СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь 2018 ел г.Мензелинск № 10

**Советның 14.12.2011 елда кабул ителгән “Минзәлә муниципаль район башкарма комитетының Мәгариф бүлеге учреждениесе тибын үзгәртү турында”гы №2 карарына үзгәрешләр кертү турында**

08.10.2018 елда кабул ителгән “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты ведомствосында булган муниципаль казна учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләрнең уставына (положениеләр) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы, мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы булган хезмәт вазифаларын башкару барышында шәхси кызыксынучанык туу турында хәбәр итү вазифасы йөкләнүне билгеләүче тиешле учреждение (предприятие) җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре арасындагы хезмәт килешүләренә үзгәрешләр кертү турында”гы №1136 карары нигезендә, шулай ук 25.12.2008 елда кабул ителгән “Коррупциягә каршы тору” №273-ФЗ Федераль законы нигезендә, Минзәлә муниципальрайон Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” Муниципаль казна учреждениесе Положениесенә үзгәрешләр кертергә;

1.1. “Мәгариф бүлеге эшчәнлеге белән идарә итү” бүлеген түбәндәге эчтәлектәге 5.12 пункты белән тулыландырырга: “Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу”.

2. “Мәгариф бүлеге” МКУ җитәкчесе Н.С.Габдуллинны Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” Муниципаль казна учреждениесе Положениесенә үзгәрешләр кертүне уздыру буенча вәкаләтле итеп билгеләргә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, яшьләр эшләре, спорт һәм социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф. Салахов.